# Кереш сүз

Төрекләр дип хәзерге татар телендә башлыча Төркиядә һәм аңа күрше өлкәләрдә яши торган төрки халыкны атыйлар. Электә бу төрекләрне «госманлы төрекләре» дип йөреткәннәр.

Төрек теле терки телләр семьялыгының угыз төркеменә керә. Бу төркемдәге телләрнең төп үзенчәлекләре — сүз башында кайбер авазларның, мәсәлән, гомумтөрки *к-, къ-* һәм *т*-ның еш кына *г-, гъ-* һәм *д* булып яңгыраулашуы(мәсәлән, *көн* урынына *гүн, таш* урынына *даш* дип әйтелү) һәм кайбер грамматик үзгәлекләр (мәсәлән, исем төрләнешендәге кушымчаларда — *н-* элементның булмавы; татарча *кызны* — төрекчә *кызы*). Угыз төркеменә, төрекләрдән тыш, азәрбайҗаннар, төрекмәннәр, гагаузлар һәм Иран төрекләре - кашкайлар, афшарлар һ. б. керә.

Бу халыкларның борынгы уртак бабалары V—VIII гасырларда *ун угыз, тугыз угыз* исемнәре астында хәзерге Монголиянең Көнчыгыш ягында борынгы "татарлар" белән күрше һәм бергәлектә яшәгән хәлдә искә алыналар. Ул угызларның чыгышы легендар Угыз ханга нисбәт ителә (бу турыда "Угызнамә" дигән героик дастанда сөйләнелә). Х гасырда угызларның күпсанлы ишле төркемнәре Урта Азиядә, Көньяк Казакъстанда һәм Көнчыгыш Европада пәйда булалар: аларның сугышчан кавемнәре көнбатышка омтылалар. Угыз кабиләләренең Кара диңгез буйларына таба хәрәкәт иткән төркемнәре — баҗанаклар (бәҗәнәкләр, печенеглар), узлар һәм "торклар" төрле сугышларда тар-мар ителеп, ахыр чиктә кыпчак төркиләре составына керә (ул угызларның калдыкларыннан гагаузлар оешкан дип саныйлар). Угыз хәрәкәтенең көньяк юнәлеше генә уңышлы бара. Угызларның бер төркеме Сәбүктәгин җитәкчелегендә Әфганстанны яулап ала. Сәбүктәгиннең дәвамчысы Мәхмүт Газнәви — тарихта иң атаклы императорларның берсе була. Угызларның икенче зур төркеме

- легендар Сәлҗук хан токымнары җитәкчелегендә Урта Азиянең Көнбатыш ягын һәм Иранны яулап алалар. Иран буйлап таралган сәлҗукый угызларның бер төркеме тагын да Көнбатышка омтыларак, Византия чикләренә барып чыга һәм 1071-елда Византия гаскәрләрен тар-мар итеп, Көньяк Азәрбайҗанны яулап алалар (кайбер терки кабиләләр ул якларга V гасырда ук үтеп кергән була).

Күпгасырлык сәяси көрәш тәҗрибәләре булган Иран-фарсы феодаллары төркиләрне үз илләреннән кысрыклый башлыйлар. Угызларның бер өлеше Ираннан төньяк-көнчыгышка чигенеп, төрекмән халкының җәтдәләрен (бабаларын) хасыйл итә, ә көнбатышкарак киткән кабиләләр хәзерге азәрбайҗан һәм төрек халыклары булып оешалар.

Хәрби оешмалары камил һәм җитәрлек дәрәҗәдә көчле булулары нәтиҗәсендә Анатолия угызлары (алар составына кайбер кыпчак кабиләләре дә кушыла) тиз арада бөтен шәрекъның диярлек хакимнәре булып әвереләләр. Бу вакытларда (XI гасырдан башлап) мөселманлыкка чыккан төрки халыкларга ислам дине яңа көч кертеп җибәрә.

Анатолия өлкәләренә бәреп кергән төрки кабиләләр башта таркау хәрәкәт итәләр. Алар еш кына үзара көрәшкә вакыт һәм көч әрәм итеп, гомуми процессны әкренәйтәләр. Ләкин XIII гасырда Анатолиядә берләштерүче көч - Госман би һәм аның варислары пәйда булып, XIV гасырда куәтле бердәм төрек дәүләте төзелә. Берничә гасыр дәвамында госманлылар Балкан ярымутравын, аннары барча гарәп илләрен диярлек яулап алалар. Нилның югары агымнарына барып чыгалар. Госманлы патшалар үзләрен барлык мөселманнарның башлыгы - хәлифә дип игълан итәләр.

Госманлы дәүләте тарихта күрелгән иң зур империяләрнең берсе була. Ләкин XVI гасырда ук госманлыларның тирән эчке зәгыйфьлекләре күренә

башлый: алар, сугышлар белән мавыгып, дәүләтнең эчке төзелешен камилләштерүгә, җитештерүчән хуҗалыкка тиешле игътибар бирмиләр һ. б. Ләкин төрекләрнең хәрби куәте әле XVIII гасыр башларында да Европа дәүләтләренең теләсә кайсыныкыннан көчлерәк була. Тик бу куәт ваклана, төрле юнәлештә хәрәкәт итә. XVIII гасыр урталарыннан башлап төрекләрнең барлык сугышлары җиңелү белән тәмамлана. Бу күңелсез "традиция" госманлы империясенең бетерелүе һәм Төркия җөмһүрияте төзелү белән генә туктала.

1920 елда атаклы "коткару сугышы" нәтиҗәсендә хәзерге чикләрендә яңа Төркия төзелә. Дәүләт башында торган Мостафа Кәмал (Ататөрек) һәм аның көрәштәшләре төрек халкына гасырлар буенча зыян китереп килгән эчке факторларны җую юлында катгый адымнар ясыйлар.

Төркиянең тәрәккыятын тоткарлап килгән факторларның берсе — язма телнең, әдәбиятның һәм укыту һәм идарә теленең халык массалары теленнәнартык нык аерылуы була. Бу хәлнең тирән тарихый сәбәпләре бар.

Халыктан аерылган шушы тел госманлы теле дип аталган. Галимнәр госманлы теле үсешенең өч чорын билгелиләр. Иске госманлы теле чоры (XIII-XV гасырлар), урта госманлы теле чоры (XV-XIX гасырлар) һәм яңа госманлы теле чоры (XIX гасыр — гасырның башы).

"Иске госманлы теле" төрек дәүләтенең барлыкка килүе вакытында хасыйл була, ул угыз-сәлҗук кабиләләр телләренә барып тоташа. Бу чорда гарәп-фарсы сүзләре белән бик нык чуарланган, "югары стиль" дип аталган стиль барлыкка килә, Бу стиль тормышның барлык өлкәләрендә — дәүләт төзелешендә, фәндә, әдәбиятта, сәнгатьтә һ. б. кулланыла.

"Урта госманлы теле" Госманлы императорлыгының чәчәк атуы чорына туры килә.

"Яңа госманлы теле" XIX гасырның икенче яртысыннан алып XX гасырның башына кадәр дәвам итә. Бу чорда Төркиянең алдынгы эшлеклеләре, галимнәре халык теленнән ерак торган телгә реформа ясарга омтылыш ясыйлар, алар Европа телләренә, бигрәк тә француз теленә мөрәҗәгать итеп карыйлар.Әмма госманлы телен яңартырга тырышу уңай нәтиҗәләр бирми. Язу теле (әдәби тел) булган госманлы телен халык теленә якынайта алмыйлар. Бары Госманлы империясе җимерелгәч кенә, милли азатлык хәрәкәтенә бәйләнешле рәвештә тел өлкәсендә тирән үзгәрешләр ясарга мөмкинлек туа.

Шулай итеп, хәзерге төрек теле бик катлаулы тарихый һәм социаль лингвистик үсешнең нәтиҗәсе булып тора.

Хәзерге чорда төрек теле, үзенең табигый әсасында торгызылып, нык үсеш алган телләрнең берсен тәшкил итә, барлык функциональ стильләрдә киң кулланыла. Бүгенге көндә төрек телендә ун меңнән артык газет-журнал нәшер ителә, ел саен йөз мең исемдә китап дөнья күрә, мәсәлән, Истамбулда гына мең нәшрият эшли.

Хәзерге Төркия БДБнең барлык республикалары белән үзенең икътисадый, мәдәни бәйләнешләрен үстерүгә нык игътибар итә. Күпчелек республикаларда төрек лицейлары ачылды һәм ачыла, югары уку йортларында төрек бүлекләре эшл*и*. Төркиядә чит ил төркиләреннән ун меңнәрчә яшьләр урта һәм югары уку йортларында укый.

"Шималь төрекләре" дип йөртелгән татарлар борыннан ук кардәш төрек халкы белән бәйләнештә булырга омтылганнар. Күп кенә татарлар Төркиягә китеп, икенче Ватаннарын тапканнар. XX йөз башында утыз-кырык мең татар Төркиягә күчеп китә. Яңа татар прозасына нигез салган Муса Акъегетзадә үткән гасыр азакларында Төркиягә китеп, төрек телендә икътисад һәм мәдәният тарихы буенча китаплар язган, газетлар чыгарган һәм җаваплы административ эшләрдә эшләгән. XX гасырда Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр булган Йосыф Акчура,

Садрый Максуди Арсал, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди Тоган, Акдәс Нигъмәт Курат, Абдулла Баттал Таймас, Рәшит Рәхмәти Арат, Әхмәт Тимер һ. б. төрек зыялыларының башында торганнардан саналалар: аларны XX гасырда Төркиядә эшләгән иң бөек затлар исәбенә кертәләр.

Хәзерге көндә, икътисадый һәм мәдәни бәйләнешләр кечәйгән чорда тәрҗемәле сүзлекләрнең әһәмияте бик зур. Шуны истә тотып, 1997-нче елда "Татарча-төрекчә сүзлек" бастырып чыгарылды. Хәзер тәкъдим ителгән бу "Төрекчә-татарча сүзлек"тә татар һәм төрек телләрен өйрәнүчеләр өчен нигезле кулланма, тәрҗемәчеләр өчен файдалы белешмә булачак. Аны җанлы сөйләшү процессында да файдаланырга мөмкин. Шуларны искә алып, сүзлектә төрек теле лексикасының барлык тармакларыннан диярлек актуаль сүзләр китерелде, һәрсүзгә грамматик характеристика бирелде, фәнни терминнарның кайсы тармакка каравы аерылып тамгалар белән күрсәтелде.

Сүзлекне төзегәндә төрек һәм татар телләренең аңлатмалы сүзлекләре, төрекчә-русча, русча-төрекчә сүзлекләр файдаланылды.

Сүзлеккә инструкцияне Фуат Ганиев төзеде. Эш авторлар арасында түбәндәгечә бүленде:

Рифкать Әхмәтьянов — A, B, C, Ç, D, E, F, G, T хәрефләре;

Фәнүзә Нуриева — I, İ, J, H, K хәрефләре;

Рафаэль Мөхәммәтдинов - L, M, N, O, Ö, P, R, S, Ş хәрефләре;

Фуат Ганиев — U, Ü, , Y, Z хәрефләре.

Сүзлеккә материал туплауда Хәлил Ачыкгөз, Асия Рәхимова катнашты.

Кереш сүзне Рифкать Әхмәтьянов белән Фуат Ганиев яздылар.

Сүзлеккә карата булган искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин: 121019, Мәскәү шәһәре, Гоголь бульвары, 6-нчы йорт, "Инсан" нәшрияты.